ГЛАВА ОМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail: Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
“28 ” марта 2023 г.

Карар
№ 2

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында» 2015 елның 19 сентябрьдәге 6 нче номерлы карары үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 6 өлеше, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы №1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Россия Федерациясе Президентының 2009 елның 21 сентябрендәге 1065 номерлы Указы нигезләмәләрен һәм федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәвен исәпкә алып, «Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте вазифаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәүне тикшерү турында» 2015 елның 02 февралендәге ПУ-71 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл

җирлеге башлыгының 2015 елның 19 сентябрьдәге 6 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 12 пунктында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. Кушымтаның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында каралган тикшерүне үткәргәндә әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гарызнамәләрне җибәрү зарурлыгы килеп чыккан очракта, Мамадыш муниципаль районы башлыгы Татарстан Республикасы Рәисенә тәкъдим кертә. Күрсәтелгән тәкъдимгә Татарстан Республикасы Рәисе хаты проекты рәвешендә тиешле гарызнамә проекты кертелә, анда әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында каралган белешмәләр чагылдырыла.

Оператив-эзләү чаралары үткәрү кирәк булган очракта, Татарстан Республикасы Рәисе хаты проектында шулай ук тикшерү өчен нигез булып торган белешмәләр, гарызнамәләр җибәрелгән (җибәрелде) дәүләт органнары һәм оешмалар һәм аларда куелган мәсьәләләр күрсәтелә, шулай ук 1995 елның 12 августындагы № 144-ФЗ «Оператив-эзләү эшчәнлеге турында»гы Федераль законның тиешле нигезләмәләренә сылтама бирелә.»

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Т.Галиуллин